ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИE**
**19.06.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2152**

«Зеленодольск муниципаль районы Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 ннмерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын үтәү буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәне әлеге карарга кушымтада каралганча расларга.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми ( http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 19 июнендәге
2152 номерлы карарына
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ МӘГАРИФ ОЕШМАЛАРЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында (алга таба - өстәмә белем бирү оешмалары) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүнең федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән база (вазыйфаи ) окладлары күләмнәрен, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады - башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгына бәйле рәвештә, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен йә хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормасы) өчен билгеләнгән өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәренең оклады;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, бер календарь ай өчен билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын асылда эшләнгән вакытта башкарган өчен хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүнең билгеләп куелган күләме;

эш хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен дә кертеп, хезмәте өчен түләү;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының

һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) эш хакы (хезмәткәр хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә: вазыйфаи окладыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

Хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем турындагы документлар торгызылуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, тармакның аерымлык билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук аның уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокук барлыкка килгәндә, аның хезмәте өчен түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының "Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында" 2010 елның 26 августындагы № 761н боерыгы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) туры килү-килмәү турындагы документларны тикшерәләр;

ел саен өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

## II. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакының база окладларын билгеләү

2.1. Өстәмә белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту бүлеге секретаре | 25 960 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |

| | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 27 390 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тренер-укытучы | 27 500 |
| | Концертмейстер | |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Производствога өйрәтү остасы | 27 650 |
| | Педагог-психолог | |
| | Методист | |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы (укытучының профессор-укытучылар составына кертелгән вазыйфасыннан тыш) | 27 780 |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | |
| | Өлкән методист | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| Структура бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе структура бүлекчә мөдире (начальнигы) һәм башка структура бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 27 830 |
| Икенче | Балаларга белем бирү | 27 890 |

| | | |
|---|---|---|
| квалификация дәрәҗәсе | программаларын һәм өстәмә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы аерымланган структура бүлекчә мөдире (башлыгы) | |

2.2. Өстәмә белем бирү оешмаларындагы медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладьі күләме, сум |
|---|---|---|
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина ир-ат хезмәткәре) | 27 760 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина ир-ат хезмәткәре) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы ( өлкән медицина ир-ат хезмәткәре)* | 29 630 |
| "Табиблар һәм провизорлар" вазыйфалары профессиональ квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |
| * Вазыйфа буйсынуда өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булган оешмада билгеләнә. | | |

2.3. Өстәмә белем бирү оешмаларындагы мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 27 450 |
| Костюмнар бүлеге мөдире | |

| | |
|---|---|
| Мәдәни чараларны оештыручы | |
| "Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме квалификация төркеме | |
| Библиограф | 28 000 |
| Китапханәче | |
| Әйдәп баручы китапханәче | |
| Тавыш операторы | |
| Фондларны саклаучы | |
| Рәссам-сынчы | |
| Рәссам-куючы | |
| "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларының җитәкче составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 29 320 |
| Китапханәнең бүлек (секторы) мөдире | |
| Кино һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | |
| Тавыш режиссеры | |
| Куючы режиссер | |
| Сәнгать җитәкчесе | |

## III. Өстәмә белем бирү оешмаларының хезмәт хакы ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы һәм күләм күрсәткечләренең норматив саны

3.1. Эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) һәм хезмәт килешүендә әйтелгән педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында» 2014 елның 22 декабрендәге 1601 нче номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

Өстәмә белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (педагогик эш оклады өчен педагогик эш нормасы) атнага 36 сәгатьтән дә артык булмаган эш вакытының кыскартылган дәвамлылыгыннан чыгып билгеләнә, ул мөгаллимлек (уку) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимы белән каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.

3.2. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган база окладының бер сәгатенә күләм күрсәткечләрнең норматив саны түбәндәгеләрне тәшкил итә:

3.2.1. Өстәмә белем бирү оешмалары өстәмә белем бирү педагогларына, балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларыннан тыш:

15 кеше - укытуның беренче елында;

12 кеше - укытуның икенче елында;

10 кеше - укытуның өченче һәм аннан соңгы елларында.

3.1.2. Өстәмә белем бирү педагогларына, балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында концертмейстерларга:

музыка мәктәпләре (сәнгать мәктәпләренең музыка бүлекчәләре) өчен:

1 кеше - индивидуаль дәресләрдә;

10 кеше -төркем белән шөгыльләнү дәресләрендә җидееллык уку срогы булганда;

6 кеше - төркем белән шөгыльләнү дәресләрендә биш еллык уку срогы булганда;

40 кеше - җыелма белән шөгыльләнү дәресләрендә җиде еллык уку срогы булганда;

18 кеше - җыелма белән шөгыльләнү дәресләрендә биш еллык уку срогы булганда;

10 кеше - сәнгать мәктәпләре (сәнгать мәктәбе бүлекләре), сәнгать мәктәбенең гомумэстетик белем бирү бүлекләре өчен;

8 кеше - сәнгать мәктәбенең башлангыч эстетик белем бирү бүлекчәләре өчен; сәнгать мәктәбенең фольклор бүлекләре өчен

1 кеше - индивидуаль дәресләрдә;

6 кеше - фольклор хореография дәресләрендә;

10 кеше - төркем белән шөгыльләнү дәресләрендә;

20 кеше - җыелма белән шөгыльләнү дәресләрендә;

хореография мәктәпләре (сәнгать мәктәбенең хореография бүлекләре), сәнгать мәктәбенең театр сәнгате бүлекләре өчен:

1 кеше - индивидуаль дәресләрдә;

5 кеше - белгечлек предметлары буенча дәресләрдә;

10 кеше - төркем белән шөгыльләнү дәресләрендә.

3.3. Мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты (эш хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары) дәвамлылыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

3.4. Хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормасы) федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә өч яклы тармак килешүләре белән билгеләнергә мөмкин.

## IV. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

4.1. Өстәмә белем бирү оешмалары хезтәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N} + P,$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган педагогик хезмәткәрләрнең база окладды күләме;

$H_f$ - өстәмә белем бирү оешмаларында фактта эшләнгән сәгатьләр саны;

$H_N$ - өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә билгеләнгән сәгать нормасы;

Р- китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан артмаган күләмдә билгеләнә;

## V. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

5.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләрен стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

5.1.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

мактаулы исемнәр һәм тармак бүләкләре булган өчен түләү;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр;

премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

5.2. Өстәмә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренә

стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм тәртибе.

5.2.1. Квалификация категориясе (Bkk) өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә квалификация категорияләренең гамәлдә булу срогы чикләрендә гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – – 1 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,5 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |
| Структура бүлекчә җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләр тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән билгеләнә (үзгәртелә).

5.2.2. Мактаулы исемнәр һәм тармак бүләкләре ($B_{pz}$)өчен түләүләр беренче һәм икенче дәрәҗә уку- укыту ярдәмче персонал хезмәткәрләре, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр өчен өстәмә түләүләр күләме.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикалар мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең тармак бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының тармак бүләкләре, Татарстан Республикасының тармак бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзының тармак бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның тармак бүләкләре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләме күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе Мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) мактау грамотасы булган өчен өстәмә түләүләр Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) тармак бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә.

"Мәгарифтәге казанышлар өчен" күкрәк билгесе, "Мактаулы остаз" мактау билгесе,"Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы" мактау

билгесе, "Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен" күкрәк билгесе, "Яшь мөгаллим" күкрәк билгесе өчен 2 процент тәшкил итә. "Мәгарифтәге казанышлар өчен"Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, "Мактаулы остаз" мактау билгесе,"Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы" мактау билгесе, "Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен" күкрәк билгесе, "Яшь мөгаллим" күкрәк билгесе өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирү өчен нигез булып торган мактаулы исемнәр, тармак бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм тармак бүләкләре өчен түләүләр күләмен билгеләү мактаулы исемнәр һәм тармак бүләкләре бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре һәм ике һәм аннан да күбрәк тармак бүләкләре өчен түләү хезмәткәр сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

5.2.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр($B_s$), профиль буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж буенча төркемнәргә карап билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 2 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге укытуда ярдәмче персоналның вазыйфалары | беренче – икенче | 4 елдан алып 10 елга кадәр | 2,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,0 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче – дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфасы | беренче-икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |

5.2.4. Эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән, әгәр стажны раслаучы документлар өстәмә белем бирү оешмасында булса, яки стажны раслаучы кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

5.2.5. Педагогик эш стажына 3 нче таблицада каралганча мәгариф һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкче һәм методик эш исәпкә алына.

3 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган эш вакыты оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге**

| Оешманың исеме | Вазыйфа исеме |
|---|---|
| | 2 |
| Белем бирү оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирү хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү);<br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, балалар йортлары, балалар: шифаханәләр, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ. б. | Укытучылар, мөгаллимнәр, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), Ватанны саклау һәм иминлек нигезләрен оештыручы укытучылар, физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствода өйрәтү мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртүгә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машиналарында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль |

| | |
|---|---|
| | педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), директор урынбасарлары (башлыклар, мөдирләр) укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү буенча, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше, производствода укыту (эш), чит тел, укыту-очу әзерлеге буенча, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча, эшчәнлеге белем бирү (тәрбия) процессына, методик тәэмин итүгә бәйле булган уку-консультация пунктлары, логопедик пунктлар, интернатлар, бүлекләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр мөдирләре, практика мөдирләре (башлыклары), режим буенча кизү торучылар, аккомпаниаторлар, культорганизаторлар, экскурсоводлар, профессор-укытучылар составы |
| Барлык исемдәге (кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә) методик (укыту-методик) оешмалар | Сектор, кабинет, лаборатория, бүлек җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, мөдирләре, эшчәнлеге методик тәэмин итүгә бәйле фәнни хезмәткәрләр,өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр). | Җитәкче, инспектор, методик инструкторлык вазыйфалары, шулай ук белгечләрнең башка вазыйфалары (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазыйфаларда эшләүдән тыш). |
| Техник укыту бүлекләре (бюросы), производствода кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыклар (ведомстволар) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре | Штаттагы укытучылар, эшчеләрне производствода өйрәтү мастерлары, эшчәнлекләре әзерләү һәм квалификация күтәрү мәсьәләләре белән бәйле булган җитәкче, инспектор, инженер вазыйфалары, методик вазыйфалар |
| РОСТО (ДОСААФ) һәм гражданнар авиациясе мәгариф оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструкторлык, инженер-инструктор, |

| | |
|---|---|
| | инструктор һәм укытучылар составы, производствога өйрәтү мастерлары, инженерлар-инструктор-методистлар, инженерлар-очучы-методистлар |
| Оешмаларның тулай тораклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, балалар һәм яшүсмерләр белән эшли торган мәдәни-агарту оешмалары | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), балалар һәм яшүсмерләр белән эшли торган инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлары мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белеме булган очракта, тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, өлкән инженер һәм җитештерү-техник белем бирү буенча өлкән инженер , өлкән мастер һәм җитештерү буенча мастер, өлкән инспектор һәм саклау һәм режим буенча инспекторы, уку-укыту-техник кабинет мөдире, психолог вазыйфаларында эшләү (хезмәт итү) |
| Искәрмә:<br>Педагогик эш стажына түбәндәгеләр кертелә:<br>Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары, өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында һәм оешмаларында укытучылар-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр булып эшләү вакыты;<br>башка оешмаларда эшләү вакыты, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча һөнәри белем бирү оешмаларында түбәндәге тәртиптә:<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажына бернинди шартларсыз һәм чикләүләрсез түбәндәгеләр кертелә:<br>контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакыты бер хәрби хезмәт көне бер эш көне исәбеннән, ә чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты - бер хәрби хезмәт көне ике эш көне исәбеннән;<br>фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты; педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажына, аерым-аерым алганда да, тулаем алганда да, турыдан-туры шушы чорларга кадәр һәм алардан соң булган педагогик эшчәнлек алып барылган очракта, түбәндәге чорлар кертеп исәпләнә:<br>контракт һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, өлкән | |

| |
|---|
| состав, прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән ЭЭМ гаскәрләрендә, куркынычсызлык гаскәрләрендә һәм органнарында) вазыйфаларында хезмәт итү вакыты;<br>Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюз (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларында, советларында)җитәкче, инспектор, инструктор һәм башка белгечләр вазыйфаларында эшләү вакыты;<br>профсоюз органнарында сайлау вазыйфаларында;<br>Балалар фондының педагогик җәмгыятьләрендә һәм идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда;<br>Укытучылар (халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында;<br>балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яки эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, балигъ булмаганнарның хокук бозуларын кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты |

5.2.6. СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә белем бирү оешмасында яки укытыла торган фән (курс, дисциплиналар, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча эшләү вакыты һәм хезмәт итү вакыты түбәндәге аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына кертеп исәпләнә:

Ватанны саклау һәм иминлек нигезләрен оештыручы укытучыларга;

физик тәрбия укытучыларына һәм мөгаллимнәренә, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура буенча инструкторларга, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга);

хезмәткә (һөнәргә) өйрәтү, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус дисциплиналары укытучыларына, мөгаллимнәренә;

производствога өйрәтү осталарына;

өстәмә белем бирү педагогларына;

эксперименталь мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

педагог-психологларга;

методистларга;

мәдәният һәм сәнгать , музыка-педагогика, нәфис-графика, музыка урта звено (бүлекләре)белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә

балаларга өстәмә белем бирү оешмалары (мәдәният һәм сәнгать, шул исәптән музыка һәм сәнгать) укытучыларына, музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына, педагогика

училищеларының (педагогика колледжларының) музыка дисциплиналары укытучыларына, музыка укытучыларына, музыка җитәкчеләренә, концертмейстерларга.

5.2.7. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, бала йортлары тәрбиячеләренә (өлкән тәрбиячеләренә) педагогик стажга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының ясле төркеме медицина сестрасы, бала йортларының пост медицина сестрасы вазыйфаларында эшләү вакыты, ә ясле төркемнәре тәрбиячеләренә медицина вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, бу вазыйфаларда эшләгән чорда хезмәткәрнең педагогик белеме булган яки ул югары белем бирү мәгариф оешмасында яисә һөнәри белем бирү оешмасында белем алган очракта, педагогик эш стажына кертеп карала.

Оешма хезмәткәрләренең белем бирү оешмаларында төп эшеннән тыш башкарылган педагогик эш вакыты, сәгатьләп түләү шартларында аның күләме уку елында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Педагогик стажга бары тик педагогик эш башкарылган айлар гына исәпкә алына.

СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләре оешмаларында һәм хезмәт итүдәге эш профиленә, укытыла торган фәнгә (курс, дисциплина, түгәрәк) туры килүе турында конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы профсоюз органы белән килешү буенча мәгариф оешмасы җитәкчесенә бирелә.

5.3. Өстәмә белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыручы характердагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

5.3.1. Квалификация категориясе ($B_{kk}$) өчен түләүләр һөнәри квалификация төркемнәре буенча аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирү тариф-квалификация характеристикалары нигезендә каралган белгечлекләр буенча мәшгуль хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – 4 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясен төзегән орган (учреждение) боерыгы датасына нигезләнеп башкарыла.

4 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| "Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

5.3.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр($B_{pz}$) мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр өчен өстәмәләр күләме.

Совет Социалистик Республикалары Союзы составында Татарстан Республикасының, автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булу өчен өстәмәләр күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикалар мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 2 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмен билгеләү алар бирелгән көннән башлана. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә, алар булган өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча бер мактаулы исем буенча билгеләнә.

5.3.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$), хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эш озынлыгына бәйле рәвештә, һөнәри квалификация төркемнәре буенча стаж төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 5 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

5 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының урта буын һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының әйдәүче буын һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

5.4. Өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыручы характердагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

5.4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр($B_{kk}$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирү тариф-квалификация характеристикалары нигезендә каралган белгечлекләр буенча мәшгуль хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладу;

$D_{kk}$ – – 6 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясен төзегән орган (учреждение) боерыгы датасына нигезләнеп башкарыла.

6 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

5.4.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезтәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладу;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр өчен өстәмәләр күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикалар мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүнең күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикалар мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә мактаулы исемнәре булган өчен тиешле түләүләр бирелә торган исемлек әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 3 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемгә ия булган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

5.4.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр($B_s$), профиль буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәргә бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 7 нче таблицада китерелгән профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

7 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән, әгәр стажны раслаучы документлар өстәмә белем бирү оешмвсында булса, яки стажны раслаучы кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

5.4.4. Хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр($B_{sr}$) урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times \frac{D_{sr}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{sr}$-8 нче таблицада китерелгән хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

8 нче таблица

